# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

18 март, 2022 ел №81

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Биеш авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Биеш авыл җирлеге советы карар кабул итте:

1.«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас муниципаль районы җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 8 ноябрендәге 172 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлегенең Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Биеш авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 9 статьяның 3 пунктын төшереп калдырырга;

2) 10 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Муниципаль эчке алынмалар Җирлек бюджеты кытлыгын финанслау, Җирлекнең бурыч йөкләмәләрен каплау, Җирлек бюджеты счетларында калган акчаларны финанс ел дәвамында тулыландыру максатларында, шулай ук федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бюджет кредитлары бирү тәртибендә каралган Татарстан Республикасы бюджетыннан Җирлек бюджетына бюджет кредитлары бирү максатларында гамәлгә ашырыла.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Биеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек башлыгына йөкләргә.

**Биеш авыл**
**җирлеге башлыгы** **Р.А. Валиев**